**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №18-5 «12» декабрь 2025 ел.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 143-41 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында»2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Советы карар кабул итте:

1. 1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 143-41 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына (15.06.2015 №170-47, 21.10.2015 №10-2, 28.05.2018 №99-26, 12.11.2018 №114-28, 13.12.2018 №119-29, 23.05.2019 №138-33, 26.11.2019 №153-37, 26.02.2021 №26-6, 29.08.2024 №188-34, 25.11.2024 №200-37 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 4) пунктчасының 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төгәлләнмәгән объектлардан тыш, 2025-2027 елларга кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына 2 процент тәшкил итә»;

1.2. 4.1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo. tatarstan.ru

3. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин